МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.05.2023 Казан ш. № 11-51

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 29.07.2021 ел, № 11-68 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. “Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау турында” 29.07.2021ел, № 11-68 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 17.03.2023 ел № 11-20) боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

пункт 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Конкурс гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъвачыларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, аларның гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән башка квалификация таләпләренә туры килүен билгеләүдән һәм гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләү өчен дәгъвачылар арасыннан гражданинны яки гражданлык хезмәткәрен тикшерүдән һәм мондый бәяләмәләр нәтиҗәләре буенча билгеләүдән гыйбарәт.”;

«1.6 пунктта:

сигезенче абзацта “кече вазыйфалар төркеме” дигән сүзләрне “”кече вазыйфалар төркеменә” дигән сүзләргә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«в) федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда»;

2.11 пунктның икенче абзацында “һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары” дигән сүзләрне “һөнәри дәрәҗәсе, һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары” дигән сүзләргә алыштырырга;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«3.4. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) конкурска кертелми:

а) аның һөнәри белеменә, гражданлык хезмәте яки белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килмәвенә бәйле рәвештә;

б) аның белгелеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең эреләндерелгән төркемнәренә һәм әзерлек юнәлешләренә) карата квалификация таләпләренә, һөнәри яктан яңадан әзерләнүнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча (гражданлык хезмәтенең вакатнлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләрендә шундый таләпләр күздә тотылган очракта) алынган квалификациягә туры килмәвенә бәйле рәвештә;

в) гражданлык хезмәтенә керүгә һәм аны үтүгә бәйле чикләүләр һәм дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законында билгеләнгән чикләүләр сәбәпле.»;

3.6 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«белеме һәм (яки) квалификациясе турында документлар күчермәләре, шулай ук, гражданинның теләге карап, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар күчермәләре, нотариуста яки хезмәт итү (эш) урыны буенча кадрлар хезәте раслаган);»;

4.1 пунктта “һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары” дигән сүзләрне “һөнәри дәрәҗәсе, һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары” дигән сүзләргә алыштырырга»;

4.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министр карары нигезендә, гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына карата гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентларында белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләндерелгән төркемнәренә), һөнәри яктан яңадан әзерләүнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә карата квалификация таләпләре билгеләнергә мөмкин.»;

4.3 пунктта “һөнәри дәрәҗәсе” дигән сүзләрдән соң “, һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары” дигән сүзләрне өстәргә;

5.2 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданинның (гражданлык хезмәткәренең) һөнәри белем дәрәҗәсенә, гражданлык хезмәте яи белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә, һөнәри дәрәҗәгә туры килүен тикшерү, шулай ук министрның тиешле карары булганда – белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләндерелгән төркемнәренә), һөнәри яктан яңадан әзерләүнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә карата туры килүен тикшерү.».

5.8 пунктның өченче абзацында «конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү” дигән сүзләрдән соң “һөнәри дәрәҗәсе” дигән сүзләрне өстәргә,»;

5.11 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс үткәрелгәндә, конкурс комиссиясе кандидатларны белемен һәм (яки) квалификациясен, гражданлык хезмәтен яки башка дәүләт хезмәтен үтүе, башка хезмәт эшчәнлеген алып баруы турында тапшырылган документлары нигезендә, бәяли, шулай ук конкурс процедуралары нигезендә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларына каршы килмәгән кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү ысулларын кулланып, индивидуаль әңгәмә, анкета үткәрә, төркемләп дискуссияләр уздыра, кандидатлар дәгъва кылган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләр буенча реферат яздыра яки тест уздыра.Конкурс үткәрелә торган вазыйфалар төркеменә һәм категорияләренә бәйле рәвештә, төрле ысуллар кулланылырга мөмкин. Шул ук вакытта кандидат белән тест уздыру һәм индивидуаль әңгәмә үткәрү барлык кандидатлар өчен мәҗбүри ысуллар булып тора.»;

5.11.5 пунктның өченче абзацында “бәяләү” дигән сүздән соң “һөнәри дәрәҗәсен” дигән сүзләрне өстәргә,»;

2. Бу боерыкның 2023 елның 29 апреленнән килеп чыккан хокукый мөнәсәбәтләргә кагылуын билгеләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин